**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

# КАРАР

№ 266 09.09.2020 ел.

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затларга, контроль-хисап органы рәисенә айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен, муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәрен арттыру турында

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы социаль гарантияләрне тәэмин итү, даими нигездә муниципаль вазыйфаны биләүче затларга, контроль-хисап органы рәисенә, муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт хакын түләүне тәртипкә салу һәм камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең акчалата бүләкләү һәм муниципаль хезмәткәрләрнең айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы карары нигезендә. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елның 1 октябреннән, Аксубай муниципаль районы Советының «Аксубай муниципаль районы муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затларга, контроль-хисап органы рәисенә айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен, муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәрен арттыру һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 26.04.2018 ел, №138 карары белән расланган, даими нигездә муниципаль вазыйфаны биләгән затларга, контроль-хисап органы рәисенә айлык акчалата түләү күләмен 1,03 тапкыр арттырырга.
2. 2020 елның 1 октябреннән Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында, Аксубай муниципаль районы Советының «Аксубай муниципаль районы муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затларга, контроль-хисап органы рәисенә айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен,

муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәрен арттыру  һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 26.04.2018 ел, №138 2018 елның карары белән урнаштырылган тәртиптә билгеләнә торган, муниципаль хезмәткәрләрнең алар биләгән муниципаль хезмәт вазыйфалары нигезендә вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттырырга.

3. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмен исәпләү өчен, әлеге карарның 2 пункты нигезендә, авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладының күләмен 1,03 тапкырга индексацияләргә һәм аны 11 498 сум күләмендә билгеләргә.

4. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Аксубай муниципаль районы сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aksubayevo.tatarstan.ru.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Аксубай муниципаль районы башлыгы,
Совет Рәисе К. К. Гилманов